# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 1 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 нчы кушымтаның тугызынчы абзацында «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 50, 49, 48, 47 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап» сүзләрен «Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы чиге буйлап» сүзләренә алмаштырырга;

2) 24 нче кушымтаның сигезенче абзацында «600 м төньяк-көнчыгышка таба Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы чиге буйлап, шуннан соң шул ук юнәлештә «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 135, 136, 131 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап» сүзләрен «төньяк-көнчыгышка таба Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы чиге буйлап» сүзләренә алмаштырырга;

3) 25 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацта «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 50, 49, 48, 47 нче урман кварталларының төньяк чиге буйлап» сүзләрен «Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы чиге буйлап» сүзләренә алмаштырырга;

б) бишенче абзацта «600 м төньяк-көнчыгышка таба Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы чиге буйлап, шуннан соң шул ук юнәлештә «Зеленодольск урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Краснооктябрьск участок урманчылыгындагы 135, 136, 131 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап» сүзләрен «төньяк-көнчыгышка таба Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгы чиге буйлап» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 21 декабре
№ 89-ТРЗ